КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 июнь г.Казань № 464

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 952 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 29 апрель, 359 нчы; 2019 ел, 6 сентябрь, 797 нче; 2019 ел, 25 октябрь, 957 нче; 2020 ел, 31 гыйнвар, 62 нче; 2020 ел, 11 февраль, 98 нче; 2020 ел, 12 май, 381 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

сиксәненче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 22 пунктындагы 1 пунктчасында каралган

иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүне һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турындагы бәяләмәләрне бирүне гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәгариф өлкәсендә муниципаль идарәне гамәлгә ашыручы муниципаль районнарның, муниципаль һәм шәһәр округларының башкарма-боеру органнарының (җирле администрацияләрнең) вазыйфаи затларын (җирле администрацияләр башлыклары урынбасарлары, җирле администрацияләрнең структур бүлекчәләре җитәкчеләре яисә җирле администрацияләрнең тармак органнары җитәкчеләре) билгеләнүне килештерүне гамәлгә ашыра һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен билгели;»;

3.5 пунктның унсигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын тикшереп тору өчен кирәкле башка документлар һәм мәгълүмат;».

2. Бу карарның 1 пунктының дүртенче абзацы 2020 елның 15 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин